**Татарстан Республикасы Азнакай район Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 52-7 «16» апрель 2021 ел

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2006 елның 14 июлендәге 63-9 номерлы «Азнакай шәһәре һәм Азнакай муниципаль районы буенча гражданнарга социаль наем һәм Дәүләт торак программалары буенча торак бирү һәм исәпкә куелганда торак мәйданы нормалары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында (25.08.2015 ел, № 389-55 карар редакциясендә)

Дәүләт программалары кысаларында социаль наем шартнамәсе буенча торак бирү өчен төрле мәйданда торак төзү планлаштырыла торган яңа федераль һәм республика программаларын бәяләү һәм формалаштыру максатларында,

**Азнакай район Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2006 елның 14 июлендәге 63-9 номерлы«Азнакай шәһәре һәм Азнакай муниципаль районы буенча гражданнарга социаль наем һәм Дәүләт торак программалары буенча торак бирү һәм исәпкә куелганда торак мәйданы нормалары турында» карарына (25.08.2015 ел, №389-55 карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«2. Социаль наем шартнамәсе буенча һәм Дәүләт торак программалары буенча гаиләнең бер әгъзасына 18 кв. м күләмендә торак урыны мәйданы бирү нормасын билгеләргә.».

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Азнакай район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләнә.

Рәис М. З. Шәйдуллин